**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Созвездие-Йолдызлык» республика фестиваль хәрәкәтенә ярдәм итү буенча чаралар турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

«Созвездие-Йолдызлык» республика фестиваль хәрәкәтенә ярдәм итү буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы совет эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Созвездие-Йолдызлык» республика фестиваль хәрәкәтенә ярдәм итү буенча чаралар турында» 2006 елның 29 апрелендәге ПУ-165 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2007 елның 16 июлендәге ПУ-357 номерлы, 2007 елның 17 декабрендәге ПУ-686 номерлы, 2009 елның 17 апрелендәге ПУ-208 номерлы, 2012 елның 20 августындагы ПУ-682 номерлы, 2012 елның 7 декабрендәге ПУ-1043 номерлы, 2015 елның 17 мартындагы ПУ-290 номерлы, 2015 елның 16 октябрендәге ПУ-992 номерлы, 2017 елның 16 июнендәге ПУ-508 номерлы, 2018 елның 14 мартындагы ПУ-231 номерлы һәм 2018 елның 14 маендагы ПУ-369 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) «Созвездие-Йолдызлык» республика фестиваль хәрәкәтенә ярдәм итү буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы совет турында нигезләмәдә:

5 пунктта «5. Совет» сүзләрен «Совет» сүзенә алмаштырырга;

8 пунктта «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

б) «Созвездие-Йолдызлык» республика фестиваль хәрәкәтенә ярдәм итү буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы совет (алга таба – Совет) составында:

Совет составыннан В.А. Леоновны, Р.М. Гарифуллинны чыгарырга;

Совет составына кертергә:

Фәттахов Дамир Илдус улын – Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрын, аны Совет рәисе урынбасары итеп расларга;

Сөләйманов Тимур Җәүдәт улын – Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрының беренче урынбасарын, аны Советның җаваплы секретаре итепasларга;

Совет әгъзаларының вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

М.Б. Борисовның – «Россия Федерациясенең атказанган сәнгать эшлеклесе, профессор, Евгений Вахтангов исемендәге Дәүләт академия театры каршындагы Борис Щукин исемендәге Театр институтының режиссура кафедрасы мөдире, Россия театр сәнгате институты – ГИТИС эстрада сәнгате кафедрасы мөдире (килешү буенча)»;

З.Д. Сөнгатуллинаның – «профессор, Н.Г. Жиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясенең вокал сәнгате кафедрасы мөдире (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2019 ел, 27 август
№ ПУ-499